ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**« 14 » декабрь 2023 ел.** **№ 28**

**Арча муниципаль районы «Наласа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Наласа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясе өлешләрендә) гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Наласа авыл җирлеге Советының 2022 елның 04 августындагы 57 номерлы карары нигезендә, җыеннарда кабул ителгән 16.11 2023 №1, 17.11. 2023 №2 карарларны гамәлгә ашыру максатында, Наласа авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Арча муниципаль районы «Наласа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: ТР,Арча районы,Наласа авылы, М.Вахитов урамы,64 йорт,ТР, Арча районы, Урта Бирәзә авылы, Татарстан урамы, 90 йорт
3. «Наласа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында» Наласа авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 23 декабрендәге 30 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Наласа авыл җирлеге башлыгы И.Р.Шакирова

Наласа авыл җирлеге
башкарма комитетының
14 декабря 2023 ел, № 28
карарына 1 нче кушымта

**Арча муниципаль районы «Наласа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип (алга таба –Тәртип) Арча муниципаль районы «Наласа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү Арча муниципаль районы «Наласа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан, аларның җыеннарда катнашуына һәм тавыш бирүдә белдергән мөнәсәбәтләренә карамастан, 2024 елның 23 февраленә кадәр түләнелә.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләре үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары (бергә яшәүче ата-аналары, ир /хатын, балигъ булган балалар).

4. Гражданнарның аерым категорияләре өчен:

а) балачактан инвалидлар өчен түләү күләме җирле җыеннар карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

5. Түбәндәге нигезле сәбәпләр булганда:

а) гаилә әгъзасының үлеме (ата-анасы, хатыны/ире, балалары),

б) янгын яки башка табигый бәла-казалар нәтиҗәсендә зыян күрү,

гражданнарга гариза нигезендә өч айдан да артмаган вакытка түләү кертү кичектерел торыла.

6. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында хәбәр (хәбәрнамә) бланкы гражданнарга мәгълүматны бастырып чыгару (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итү һәм гражданнарның күпләп җыелу урыннарындагы мәгълүмат стендларында, шулай ук почта элемтәсе аша җибәрү юлы белән җиткерелә.

Хәбәрдә (хәбәрнамәдә) гражданнарның үзара салым акчаларын кертү өчен түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

7. Гражданнарның үзара салымыннан җыелган акчалар Арча муниципаль районы «Наласа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәхси счетына күчерелә.

8. Гражданнарның түләүләре физик затлар кушуы буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия оешмалар аша, почта күчерүе (исәп-хисап оешмалары) яисә Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша https://uslugi.tatarstan.ru сылтамасы буенча акча күчерү юлы белән башкарыла.

9. Түләү фактын касса кереме ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар раслый.

10. Гражданнарның билгеләнгән срокка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Наласа авыл җирлеге
башкарма комитетының
14.12.2023 ел, №28
карарына 2 нче кушымта

ХӘБӘР (ХӘБӘРНАМӘ) № _______

«______________________авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер мәртәбә түләнә торган түләү турында

Түләүченеең Ф.И.А.и ____________________________
Адресы:__________________________________________________________
___________________________________________________________нигезендә
Сезгә ______________________________ вакытка кадәр ______________________________ сум күләмендә чараларны гамәлгә ашыруга бер тапкыр түләнелә торган түләү түләргә кирәк.
Түбәндәге реквизитлар буенча:_____________________________________________
БИК банк ____________________________
Сч. № _______________________________________
Счетны алучы № _____________________________
ИНН _____________________________________________
КПП _____________________________________________